| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.02.2023 Баулы шәһәре №34

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 133 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 284-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 133 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.»;

2 нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.8.2.1. пунктындагы 6) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1, 3 һәм 4 бүлекләрендә каралган максатларда гавами сервитут билгеләү турында үтенечнамә бирелгән очракта, линия объектлары булып торучы инженерлык корылмаларын капиталь ремонтлау максатларында гавами сервитут урнаштыру зонасы, автомобиль юлы, тимер юллар урнаштыру зонасы территориясен планлаштыру документациясенә туры килмәсә, шулай ук мондый инженерлык корылмаларын капиталь ремонтлау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров